ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

2023 елда Татарстан Республикасы Дәүләт Советы эше турында мәгълүмат хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшинның 2023 елда Татарстан Республикасы Дәүләт Советы эше турындагы мәгълүматын тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. 2023 елда Татарстан Республикасы Дәүләт Советы эше турындагы мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларына:

2.1. Гражданнар мөрәҗәгатьләрен, гражданнар җыеннарында, сайлау кампанияләре барышында республика халкыннан кергән наказларны һәм тәкъдимнәрне карау эшен системалы нигездә дәвам итәргә.

2.2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативаларын, Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисенә, Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы Рәисенә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгатьләрен үткәрүне контрольдә тотарга.

2.3. Россия Федерациясе тышкы сәясәтенең яңартылган концепциясен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Россия Федерациясе субъектлары, башка дәүләтләр парламентлары һәм халыкара парламент оешмалары белән хезмәттәшлегенең якынча планы нигезендә парламентара хезмәттәшлек линиясе буенча, шул исәптән чит илләрдә яшәүче ватандашлар белән хезмәттәшлек буенча, регионара һәм халыкара багланышларны алга таба үстерүгә ярдәм итәргә.

2.4. Россия Федерациясе Федераль Собраниесенең, Идел буе федераль округы Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару органнарының профильле комитетлары белән уртак күчмә утырышлар үткәрү тәҗрибәсен дәвам итәргә.

2.5. Булачак Россия Федерациясе Президентын сайлауларны (2024 елның 15 – 17 марты) һәм җиденче чакырылыш Татарстан

Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлауларны (2024 елның сентябре) әзерләүдә һәм хокукый тәэмин итүдә актив катнашырга.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларына:

3.1. 2024 елда Казан шәһәрендә үткәрелә торган халыкара һәм федераль дәрәҗәдәге чараларда (БРИКС башлыклары Саммиты, «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» халыкара икътисадый форумы, «Киләчәк уеннары» халыкара мультиспорт турниры һәм башкалар) актив катнашырга.

3.2. Депутатларга беркетелгән сайлау округларында Россия Федерациясендә Гаилә елы, Татарстан Республикасында Фәнни-технологик үсеш елы кысаларында үткәрелә торган чараларда актив катнашырга.

3.3. Традицион гаилә кыйммәтләрен саклап калу, зур гаиләнең абруен һәм дәрәҗәсен, аның социаль һәм хокукый яклануын арттыру, үсеп килүче буынны тәрбияләү буенча планлы эш алып барырга.

3.4. Махсус хәрби операциядә катнашучыларга, аларның гаилә әгъзаларына һәрьяклап ярдәм күрсәтүне дәвам итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 18 декабре
№ 2315-VI ДС